| Республика Татарстан Совет Абалачевского сельского поселения Менделеевского муниципального района Республики Татарстан | Татарстан Республикасы Менднлеев муниципаль районы Абалач авыл Җирлеге Советы |
|---|---|
| Решение<br>2020 елның 28 июленнән | Карар<br>№ 143 |

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча карар проекты турында

Россия Федерациясендә үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 19 статьясы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2018 елның 5 сентябрендәге 79 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск районы «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2013 елның 31 маеннан 84 номерлы Абалач авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләреннән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләрен Россия Федерациясе Икътисадый үсеш Министрлыгының 2014 елның 01 сентябрендәге 540 номерлы Боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре Классификаторына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советының 2013 елның 24 маеннан 79 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының “Абалач авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 3 өлешнең II бүлегендәге 35 статьясында «Ж1» бүлегенең 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчемсез милектән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:

- индивидуаль торак төзелеше өчен;

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге);
- участоклары булган блокланган бер гаилә йортлары;
- балалар бакчалары, мәктәпкәчә тәрбия бирүнең башка объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр.»

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советы Карары проектын карап тикшерү буенча гавами тыңлаулар 2020 елның 14 августында 16 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Абалач авыл җирлеге, Абалач авылы, Үзәк урамы, 35 й., Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге мәдәният йорты бинасының актлар залы.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

4. Комиссиягә «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең “Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советы карар проекты белән танышу чорында югарыда күрсәтелгән проектның демонстратив материаллары экспозициясен оештырырга, кызыксынган затларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен түбәндәге адрес буенча кабул итәләр: Татарстан Республикасы, Абалач авыл җирлеге, Абалач авылы, Үзәк урамы, 35 й., Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге мәдәният йорты бинасының актлар залы;

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында бастырырга, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Абалач авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Абалач авыл җирлеге
Советы рәисе И.Ш. Исрафилов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Абалач авыл җирлеге Советының
2020 елның 28 июленнән
143 номерлы карарына

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Абалач авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча комиссия составы

1. Рәис: Исрафилов Илнар Шамил улы - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;
2. Рәис урынбасары: Белов Николай Сергеевич - Абалач авыл җирлеге Советы Депутаты;
3. Секретарь: Марданова Надежда Николаевна – Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре;
4. Комиссия әгъзасы: Шаихов Илдар Шәйхегур улы - Абалач авыл мәктәбе директоры;
5. Комиссия әгъзасы: Шияпова Ландыш Альбирт кызы – Абалач авыл җирлеге Советы Депутаты;
6. Комиссия әгъзасы: Хәбиров Равил Зөфәр улы – Менделеевск муниципаль районы Инвестицион һәм инфраструктур үсеш идарәсенең проектлау бүлеге башлыгы.